ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫ£
ЭТИЛ СПИРТЫ һ¥М АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ¡ИТЕШТЕРYНЕ,
¥ЙЛ¥НЕШТ¥ ЙЇРТYНЕ,
СЫЙФАТЫН Д¥УЛ¥Т ТИКШЕРYЕН
Т¥ЭМИН ИТУ һ¥М КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
Д¥УЛ¥Т ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

# ПРИКАЗ

03.12.2018 № 12–07 / 230

Казан ш.

“Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 01.02.2018 ел, № 12-07/7 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

“Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 01.02.2018 ел, № 12-07/7 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законга туры китерү максатыннан чыгып, б о е р ы к б и р ә м:

1. “Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 01.02.2018 ел, № 12-07/7 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольлектә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Ж.Й.Әхмәтханов

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь
инспекциясенең 03.12.2018ел,
№ 12-07/230 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 01.02.2018 ел, № 12-07/7 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1нче бүлектә:

1.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шулай ук ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең эш графигы турында мәгълүматларны алырга мөмкин:

1) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе бинасында урнаштырылган, дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында визуаль һәм тестлы мәгълүматлардан торган мәгълүмати стендлар аша.

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүматлар Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламентының (алга таба – Регламент) 1.3.1, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлардан тора.

2) «Интернет» челтәре аша:

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында (https:// gosalcogol.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефон аша) ;

4) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) (электрон почта адресы – gosalcogol@tatar.ru)”;

1.5 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күп функцияле үзәкнең читтәге эш урыны – “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында”

22.12.2012 ел, №1376 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округы) шәһәр яисә авыл җирлегендә булдырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур подразденеиесе (офисы).”;

2 нче бүлекнең “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге”графасында:

2.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, лицензия бирүне, озайтуны, лицензияне яңадан рәсмиләштерүне кертеп, мөрәҗәгать итүчедән тиешле лицензия алу өчен тапшырыла торган документлар алынганнан соң 15 эш көненнән артмый”;

2.9 пунктның икенче абзацына “, яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле лицензия алу өчен күздә тотылган документларны тулысынча тапшырмау;” дигән сүзләрне өстәргә”;

5 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (белгече) яки дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр түбәндәгеләрнең гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр тәртиптә шикаять белдерүгә хокуклы:

бүлек белгече гамәлләренә (гамәл кылмау) карата – ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә;

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе кабул иткән карарларга шикаятьләр буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән, түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү срогы санга сугылмаганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы санга сугылмаганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүматлар яисә гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту, баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең

башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаганда;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп иткәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы санга сугылмаганда;.

8) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе санга сугылмаганда;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү туктатып торылганда, туктатып торуга нигезләр федераль законнар һәм шулар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә күздә тотылмаган очракта;

10) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда, кирәк, дип һәм (яки) дөрес түгел, дип күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматлар таләп ителгәндә, №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында күздә тотылган очраклардан тыш.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтыннан (https:// gosalcogol.tatar.ru.), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларын кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерелү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын санга сукмауга карата шикаять белдерелү очрагында – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелә торган вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә атамасы, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары)

(булганда) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Бу пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм, мөрәҗәгать итүченең теләге буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять, канәгатьләндерелек, дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатыннан, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан кылына торган гамәлләр турында мәгълүматлар бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу максатыннан мөрәҗәгать итүчегә алга таба нинди гамәлләр кылырга кирәклеге күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне канәгатьләндереп булмый, дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән караларның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүматлар бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.”